КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 декабрь г.Казань № 1232

Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 7 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк дәүләт төзелеш контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне расларга.
2. Бу карар (бу карар белән расланган Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге турындагы нигезләмәнең 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган VIII бүлегеннән тыш) 2021 елның 31 декабреннән үз көченә керә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин